**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ**
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

# ПРИКАЗ

__13.12.2019____ № 10-07/203___

г.Казань

Татарстан Республикасы
территориясендә алкогольле
продукцияне ваклап сатуны һәм
җәмәгать туклануы хезмәтләрен
күрсәткәндә алкогольле продукцияне
ваклап сатуны лицензияләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау
турында

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасын камилләштерү максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 1 февралендәге 12-07/7 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 1 февралендәге 12-07/7 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 декабрендәге 12-07/230 номерлы боерыгын.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Җитәкче** **Җ.Й.Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2019 елның 13 декабрендәге 10-07/203 номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуга (авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр тарафыннан шәраб, күбекле шәраб (шәмпан шәрабы) ваклап сатуны лицензияләүдән тыш) һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүне, лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтуны, лицензиянең (алга таба – лицензия) гамәлдә булуын яңартуны һәм гамәлдән чыгаруны үз эченә алган дәүләт хезмәте (алга таба - хезмәт) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе (алга таба - ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе) һәм аның территориаль органнары тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең урнашу урыны: 420107, Казан шәһәре, Һ.Такташ ур., 94 й., кабул итү бүлмәсе телефоны (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92.

Территориаль органнар турында мәгълүмат (атамасы, адресы, хезмәт күрсәтелә торган муниципаль берәмлекләр, телефон, җәмәгать транспорты тукталышлары) 15 нче кушымтада күрсәтелгән.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм Казан территориаль органының эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30-17.30 сәгатьләрдә, җомга 8.30-16.15 сәгатьләрдә, төшке аш 12.00-12.45 сәгатьләрдә.

Документлар кабул итү графигы: дүшәмбе, чәршәмбе 9:00-12:00 сәгатьләрдә; сишәмбе, пәнҗешәмбе 13:00-16:00 сәгатьләрдә.

Җәмәгать транспортында «Һади Такташ урамы» тукталышына кадәр барырга:

- 5, 25, 43, 68, 71, 77 номерлы автобуслар.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Әлмәт, Арча, Яшел Үзән, Түбән Кама, Чаллы, Чистай территориаль органнарының эш графигы: шимбә һәм

якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 8.00дән 17.00гә кадәр, җомга 8.00-15.45 сәгатьләрдә, төшке аш 12.00-12.45 сәгатьләрдә.

Документлар кабул итү графигы: дүшәмбе, чәршәмбе 9:00-12:00 сәгатьләрдә; сишәмбе, пәнҗешәмбе 13:00-16:00 сәгатьләрдә.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм Казан территориаль органына пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документ белән узарга мөмкин.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең башка территориаль органнарына керү - ирекле.

1.3.2. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең лицензияләү бүлеге (алга таба - Лицензияләү бүлеге) белешмә телефоны: 278-91-99.

Башка территориаль органнарның белешмә телефоннары 15 нче кушымтада күрсәтелгән.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтының адресы: http://gosalcogol.tatar.ru. Электрон почта адресы: cla@tatalc.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Лицензияләү бүлеге һәм ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнарының урнашу урыны, эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша. Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (алга таба - Регламент) 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында (https://gosalcogol.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яки аның территориаль органнарына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яисә аның территориаль органнарына язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы gosalkogol@tatar.ru);

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, шулай ук электрон почтасы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, дәүләт

һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарының урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында Лицензияләү бүлеге белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче өлеш), 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба - РФ Салым кодексы) («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 2000, № 32, 3340 ст.);

«Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 171-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, №48, 4553 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президент Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 елның 5 августындагы 391 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмә (алга таба - 2005 елның 5 августындагы 391 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары белән расланган нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 10.08.2005, №30, 0725 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган (алга таба – №880 ТР МК карары) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ

регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.; 20.12.2011, №48, 2612 ст.; 25.05.2012 ел, №40, 1252 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Алкогольле продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларның түләнгән устав капиталының минималь күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары һәм карар нигезләмәләрен гамәлдән чыккан дип тану турында» 2014 елның 15 мартындагы 161 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №161 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 25.03.2014, 20.05.2014, № 37, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Юстиция министрлыгында 2018 елның 19 декабрендә теркәлгән 53063 номерлы «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерүгә һәм әйләнешкә кертүгә лицензия формасы турында» 2018 елның 14 августындагы 172н номерлы Россия Финанс министрлыгы боерыгы («Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы») (www.pravo.gov.ru) 20.12.18).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

алкогольле продукция - азык чималыннан җитештерелгән этил спиртын һәм (яки) спиртлы азык-төлек продукциясен кулланып яки кулланмыйча җитештерелгән, әзер продукция күләменең 0,5 проценттан артыгын этил спирты тәшкил иткән азык-төлек продукциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлек нигезендәге азык-төлек продукциясеннән тыш. Алкогольле продукция спиртлы эчемлекләр (шул исәптән аракы, коньяк), шәраб, җиләк-җимеш шәрабы, ликер шәрабы, күбекле шәраб (шәмпан шәрабы), шәраб эчемлекләре кебек төрләргә бүленә;

алкогольле продукцияне ваклап сату - товар китерү шартнамәсе буенча алкогольле продукцияне сатып алу (импорттан тыш), шулай ук сатып алынган алкогольле продукцияне саклау һәм аны ваклап сату-алу шартнамәсе нигезендә сату белән бәйле эшчәнлек төре;

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату - товар китерү шартнамәсе нигезендә алкогольле продукцияне сатып алу (импорттан тыш), саклау (шул исәптән ачылган куллану тарасында (савытта), алкогольле эчемлекләр, кулинария ризыкларын, спиртлы продукция һәм башка азык-төлек продукциясен җитештерү өчен куллану, җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә кулланучыга алкогольле продукцияне ачылган кулланучы тарасында яки агызып сату белән бәйле эшчәнлек төре;

лицензияләүче орган - ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе;

лицензия - юридик зат тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сатуны яки җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле

продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыру хокукына лицензияләүче орган тарафыннан кәгазьдә бирелгән документ белән расланган махсус рөхсәт;

лицензия таләпләре - лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашырганда лицензиат тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр җыелмасы;

лицензиягә дәгъва итүче - лицензияләүче органга алкогольле продукцияне ваклап сату хокукына лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән юридик зат;

лицензиат - алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыру өчен лицензиягә ия булган юридик зат;

мөрәҗәгать итүче (лицензиягә дәгъва итүче) - лицензияләүче органга лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән юридик зат;

гариза - 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать. Гариза формалары әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында, 6 нчы кушымтасында, 7 нче кушымтасында, 8 нче кушымтасында, 9 нчы кушымтасында, 10 нчы кушымтасында, 11 нче кушымтасында китерелгән;

этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүгә һәм әйләнешенә бирелгән, туктатып торылган һәм гамәлдән чыгарылган лицензияләрнең дәүләт җыелма реестры - бирелгән, озайтылган, яңадан рәсмиләштерелгән, туктатып торылган, яңартылган, гамәлдән чыккан һәм бетерелгән лицензияләр турында белешмәләр җыелмасы;

техник хата - лицензияне рәсмиләштергәндә лицензияләүче орган тарафыннан җибәрелгән техник характердагы (басма хата, хәреф хатасы һ. б.) хата;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү. | 171-ФЗ номерлы федераль законның 18 ст. 2 п., 4 п.; |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе. | 171-ФЗ номерлы федераль законның 6 с. 1 п., 18 ст. 10 п.; 05.08.2005 ел, №391 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 1.1 п., 3.3 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында карар һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия;<br>2) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында карар һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия;<br>3) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга гамәлдә булу вакыты озайтылган лицензия;<br>4) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга гамәлдә | 171-ФЗ номерлы федераль законның 19 ст. 7, 8, 9, 11, 12, 17 п., 20 ст. 1, 2 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | булу вакыты озайтылган лицензия;<br>5) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карар һәм яңадан рәсмиләштерелгән лицензия һәм (яки) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карар һәм яңадан рәсмиләштерелгән лицензия;<br>6) лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында карар;<br>7) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүдән баш тарту турында карар;<br>8) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүдән баш тарту турында карар;<br>9) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында карар;<br>10) лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар;<br>11) лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында карар;<br>12) лицензиат гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карар;<br>13) кире алу турында гариза нигезендә гаризаны карау процедурасын туктату турында карар. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте | Лицензия бирүне, озайтуны, яңадан рәсмиләштерүне үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты мөрәҗәгать итүчедән тиешле лицензияне алу өчен бирелә торган документлар алынганнан соң 15 эш көненнән дә артмый.<br>Өстәмә экспертиза үткәрү кирәк булганда, әлеге вакыт аны үткәрү чорына озайтыла, ләкин оешмага гаризаны карау вакытын озайту турында хәбәр юллап, 30 календарь көненнән артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | 171-ФЗ номерлы федераль законның 19 ст. 7 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Лицензиаттан лицензиянең гамәлдә булуын туктатуга китергән шартларны бетерү турында гариза алынганнан соң 14 календарь көн эчендә лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки аның гамәлдә булуын яңартудан баш тарту һәм лицензияне гамәлдән чыгару турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул ителә.<br>Лицензиатның гаризасы буенча лицензиянең гамәлдә булуын туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза белән кушып бирелгән лицензия теркәлгән көннән алып 10 эш көненнән дә артмый.<br>Лицензиягә дәгъва кылучыга яисә лицензиатка дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү гариза бирүченең мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска), дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны юллау дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла. | 17-ФЗ номерлы федераль законның 20 ст. 1 п.; |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, норматив хокукый актлар нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге,<br>аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен документлар 1 нче кушымта нигезендә тапшырыла.<br>Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен документлар 2 нче кушымта нигезендә тапшырыла.<br>Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту өчен документлар 3 нче кушымта нигезендә тапшырыла.<br>Лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен документлар 4 нче кушымта нигезендә тапшырыла.<br>Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту өчен, лицензиат лицензияләүче органга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән шартларны бетерү турында, нигезләү документларын кушып, гариза тапшыра. Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турындагы гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә: оешманың исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше, аның урнашу | 171-ФЗ номерлы федераль законның 19 ст. 3.2 - 3.2.2 п;<br>210-ФЗ номерлы федераль закон<br>63-ФЗ номерлы федераль закон<br>161 номерлы ТР МК карарының 1 п.<br>«Устав капиталын түләүне раслаучы документлар турында» 13.12.2005 ел, № ШТ-6-07/1045 Россия Федерациясе Федераль |

| | | |
|---|---|---|
| | урыны, ИНН, лицензиянең реестр һәм теркәү номеры, лицензияне бирү датасы; лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән шартлар һәм әлеге шартларны бетерү ысулы.<br>Лицензиянең гамәлдә булуын туктату өчен лицензиат 11 нче кушымта нигезендә аның гамәлдә булуын туктату турында гариза бирә.<br>Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар кабул итү сәгатьләрендә мөрәҗәгать итүче шәхси мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга мөмкин.<br>Лицензияне яңадан рәсмиләштерүгә гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннарына, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкы ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырылган. | салым хезмәте хаты |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге ведомстволар карамагында булган түбәндәге документлар (мәгълүматлар) кирәк:<br>а) Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе - Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлар; | 171-ФЗ номерлы федераль законның 19 ст. 3.2, 3.2.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | б) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе - Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлар;<br>в) Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (Татарстан) - техник мөмкинлек булганда, эшмәкәрлек эшчәнлегенең (Россия буенча) аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрләр реестрындагы мәгълүматлар.<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда, электрон рәвештә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр башкару;<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, | |

| | | |
|---|---|---|
| | шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүматны тапшыру;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматны бирү. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту бары тик түбәндәге очракларда гына мөмкин:<br>1) гариза вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылган;<br>2) тапшырылган документларда өстәп язу, чистарту, сызылган сүзләр, килешенмәгән төзәтмәләр булу, шулай ук карандаш белән башкарылган документлар, эчтәлеген аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зыян күргән документлар;<br>3) 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документ күчермәләре) тапшыру. | 210-ФЗ номерлы федераль закон<br>63-ФЗ номерлы федераль закон |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне бирү, озайту һәм яңадан рәсмиләштергән өчен дәүләт пошлинасы түбәндәге күләмнәрдә алына:<br>алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү - лицензиянең гамәлдә булу срогының һәр елы өчен 65 000 сум; | РФ Салым кодексының 333.33 ст. 1 п. 94 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | жәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү - лицензия гамәлдә булу срогының һәр елы өчен 65 000 сум;<br>лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту - алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия, җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү өчен билгеләнгән күләмдә;<br>юридик затны үзгәртеп корганда (юридик затларны кушу, берләштерү яки үзгәртү рәвешендә үзгәртеп корудан һәм үзгәртеп корылган юридик затларның хокук варисын дәүләт теркәвенә алу датасына катнашучы һәм юридик затның бер үк эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган очрактан тыш) лицензияне яңадан рәсмиләштерү - тиешле лицензия төрен бирү өчен билгеләнгән күләмдә;<br>кушу, берләштерү яки үзгәртү рәвешендә юридик затларны үзгәртеп корганда һәм үзгәртеп корылган юридик затларның хокук варисын дәүләт теркәвенә алу датасына катнашучы һәм юридик затның бер үк эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган очракта, лицензияне яңадан рәсмиләштерү - 3 500 сум;<br>юридик затның лицензиядә күрсәтелгән исеме (аны үзгәртеп кормыйча), эшчәнлек алып бару урыны яки лицензиядә күрсәтелгән башка мәгълүматлар үзгәрүгә, шулай ук лицензия югалуга бәйле рәвештә лицензияне яңадан рәсмиләштерү - 3 500 сум.<br>Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр бирү, озайту һәм яңадан рәсмиләштерү өчен оешмалар тарафыннан дәүләт пошлинасы түләү өчен счет реквизитлары:<br>Исәп-хисап счеты - 40101810800000010001<br>Банк БИК – 049205001<br>Алучы банк - Татарстан Республикасы Милли банкы бүлекчәсе | |

| | | |
|---|---|---|
| | ИНН 1654025044 КПП 165901001<br>Алучы - ТР буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе)<br>Бюджет классификациясе коды: 750 1 08 07082 01 1000 110<br>Түләүнең билгеләнеше (лицензия бирү яки озайту өчен): Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр бирү (озайту) өчен дәүләт пошлинасы».<br>Түләүнең билгеләнеше (лицензияне яңадан рәсмиләштергән өчен): Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләрне яңадан рәсмиләштергән өчен дәүләт пошлинасы»<br>ОКТМО түләүченең теркәү урыны буенча күрсәтелә -<br>ОКТМО Казан шәһәре 92 701 000<br>Чистай шәһәре 92 659 101<br>Түбән Кама шәһәре 92 644 101<br>Чаллы шәһәре 92 730 000<br>Арча шәһәре 92 612 151<br>Яшел Үзән шәһәре 92 628 101<br>Әлмәт шәһәре 92 608 101 | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать тапшырганда, мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта максималь көтү вакыты | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында кәгазьдә гариза бирү (чират булганда) – 15 минуттан да артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда чиратта максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | 601 номерлы РФ Президенты указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергәннән соң бер көн дәвамында.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче икенче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаларны тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү- | |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр. | чыгу урыны һәм алар эчендә уңайлы хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның вакыт буенча озынлыгы күрсәткече, дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләти һәм муниципаль | Дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалану мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе бинасының һәм аның территориаль органнарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инспекция бинасын һәм бүлмәләрен инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын булдыручы чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү; | 880 номерлы ТР МК карарының 2.4 п.<br>601 номерлы РФ Президенты указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүче сайлап алу буенча башкарма органның теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә Федераль законның 15.[1] статьясында каралган берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать аша (алга таба - комплекслы мөрәҗәгать) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге яисә андый мөмкинлек булмау | инвалидларга, биналарга аларның керә алу мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән аларга хезмәтне алуга комачаулаучы башка тоткарлыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре:<br>документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе яки аның территориаль органнары белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары белгечләре белән хезмәттәшлеге:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны турыдан-туры тапшырганда - бердән артык түгел (консультацияләрдән тыш);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә - бердән артык түгел (консультацияләрдән тыш).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер хезмәттәшлеге озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Лицензияне яңадан рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте КФҮдә, КФҮнең читтән торып эш урыннарында күрсәтелгәндә консультацияләрне, документларны кабул итүне КФҮ белгече, КФҮнең читтән торып эш урыннары белгечләре башкара.<br>Техник мөмкинлек булган очракта, кирәкле документларны электрон рәвештә тапшыру (КФҮ электрон санлы имзасы белән имзаланган документларның скан- | |

| | | |
|---|---|---|
| | сурәтләре) КФҮ мәгълүмат системасы аша башкарыла. Бу очракта кәгазь документлар ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм аның территориаль органнарына, КФҮ белән килешүдә күрсәтелгән вакыт дәвамында җибәрелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә, аның территориаль органнарына, КФҮгә (шәхсән яки телефон аша) телдән мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук mon.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте территориаль принцип буенча, лицензиат яисә лицензиягә дәгъва итүченең ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яисә юридик затны (мөрәҗәгать итүчене) дәүләт теркәвенә алу урыны буенча ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең тиешле территориаль органына мөрәҗәгать итү юлы белән күрсәтелә (15 нче кушымта, 16 нчы кушымта).<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы бүтән таләпләр | Консультация Интернет-кабул итү бүлмәсе аша бирелергә мөмкин.<br>Электрон рәвештә гариза һәм документлар Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша юллана, соңыннан дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда документларның оригиналларын күрсәтү мәҗбүри.<br>Документларны электрон формада тапшыру өчен мәҗбүри шарт булып, аларны электрон имза белән 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзалау тора. | 63-ФЗ номерлы федераль закон<br>210-ФЗ номерлы федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Лицензияне бирү, гамәлдә булу вакытын озайту, яңадан рәсмиләштерү, гамәлдә булуын яңарту, гамәлдә булуын туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гариза һәм документларны кабул итү, теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү;

4) лицензияне бирү, яңадан рәсмиләштерү, яңарту, туктату, гамәлдә булу вакытын озайту, бирелгән лицензияне алыштыру турында карар әзерләү һәм раслау;

5) лицензияне бирүдән, яңадан рәсмиләштерүдән, яңартудан, туктатудан, гамәлдә булу вакытын озайтудан, бирелгән лицензияне алмаштырудан баш тарту турында карар әзерләү һәм раслау;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

7) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Лицензияләү бүлегенә яисә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органына (15 нче кушымта) шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Лицензияләү бүлеге белгече яисә территориаль органның лицензияләү белгече (алга таба - лицензияләү белгече) мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Лицензияләү белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте алу турында консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк очракта, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла. Административ процедураның дәвамлылыгы, шәхси мөрәҗәгать иткән очракта, консультация бирә башлаганнан алып 15 минуттан һәм телефон аша сөйләшү башланганнан соң 10 минуттан артмаска тиеш.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм лицензия алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

3.3. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү.

3.3.1. Лицензиягә дәгъва итүче шәхсән, яисә электрон рәвештә (электрон имза белән имзаланган (таныкланган) документлар рәвешендә) яисә почта аша (белдерү кәгазе һәм кушымталар исемлеге булган кыйммәтле хат), 15 нче кушымта нигезендә, юридик затның дәүләт теркәвенә алу урыны буенча лицензияләүче органга лицензия алу турында гариза бирә (юллый) (5 нче кушымта, 6 нчы кушымта) һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Лицензия алу турындагы гаризаны мөрәҗәгать итүче җитәкчесе яки ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкаләтле зат имзалый.

Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, алу фактын раслап, электрон формада аның датасы һәм теркәү номеры күрсәтелгән җавапны юллый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында сканерланган, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивына формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.3.2. Лицензияләү белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

исемлек буенча документлар кабул итү;

шәхсән тапшырылган яки почта аша килгән яисә электрон почта аша кергән гаризаны гаризаларны теркәү журналында теркәү (12 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә кергәндә бирелгән номер, гариза һәм документларны кабул итү датасы турында тамгалы документлар исемлеге күчермәсен тапшыру (җибәрү);

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризаларны теркәү журналында теркәү һәм үтәү өчен җибәрелгән документлар.

3.3.3. Лицензияләү белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мөрәҗәгатьләрне юллый:

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә салымнар һәм җыемнар, пенялар түләү буенча бурычлар һәм салымнар һәм җыемнар турында, Россия Федерациясе законнарын бозган өчен штрафлар булу яки булмау турында мәгълүматлар тапшыру турында;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә эшмәкәрлек эшчәнлегенең (Россия буенча) аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында (техник мөмкинлек булганда).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгатьләр.

3.3.4. Кергән документлар нигезендә лицензияләү белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензия эшен формалаштыру (аерым папка туплау);

тапшырылган документларның җитәрлек булуын, рөхсәт ителүен һәм дөреслеген ачыклау өчен, шул исәптән документларның мөһерләр белән раслануына, якларның яки вәкаләтле вазыйфаи затларның тиешле имзалары булуына, документ текстларында чистарту яки өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка әйтелмәгән төзәтмәләр булмавына инанып, тапшырылган документларның закон таләпләренә туры килүенә планнан тыш тикшерү үткәрү;

Документларга планнан тыш тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча лицензияләү белгече тикшерү актын, бәяләмәне рәсмиләштерә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган лицензия эше, документар тикшерү акты, бәяләмә.

3.3.5. Документларга өстәмә экспертиза үткәрү кирәк булган очракта, лицензияләү белгече:

документларга өстәмә экспертиза билгеләү һәм гаризаны карау вакытын озайту зарурлыгы турында хезмәт язуын әзерли;

өстәмә экспертиза үткәрү турында карар проектын әзерли;

лицензияләүче орган җитәкчесенә кул кую өчен әзерләнгән документларны җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: документларга өстәмә экспертиза билгеләү һәм гаризаны карау вакытын озайту зарурлыгы турында хезмәт язуы, карар проекты.

3.3.6. Лицензияләүче орган җитәкчесе өстәмә экспертиза үткәрү турында карар кабул итә, документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында карарга кул куя (уңай карар кабул ителгән очракта) һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: өстәмә экспертиза үткәрү турында карар - кул куелган карар.

3.3.7. Лицензияләү белгече, тапшырылган документларга өстәмә экспертиза үткәрү зарурлыгына бәйле рәвештә, гаризаны карау срогын озайту кирәклеге турында карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.3.5-3.3.6 пунктчаларында билгеләнгән процедуралар өстәмә экспертиза үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында карар.

3.3.8. Лицензияләү белгече, дөрес белешмәләр алу максатыннан, тиешле дәүләт органнарына мөрәҗәгатьләр җибәрүне гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән мөрәҗәгатьләр.

3.3.9. Алынган мәгълүматлар нигезендә лицензияләү белгече:

тапшырылган документларның алынган мәгълүматларга туры килүенә анализ ясый;

документларга өстәмә экспертиза үткәрә;

бәяләмә әзерли.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң биш эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмә.

3.3.10. Лицензия бирү турында гариза биргән мөрәҗәгать итүчегә яки лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза биргән лицензиатка карата планнан тыш документар һәм планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрелә. Планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламенты белән билгеләнгән.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерү акты.

3.3.11. Тикшерү бәяләмәсе һәм актлары нигезендә лицензияләү белгече:

лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

әзерләнгән карар проектын, лицензия эше белән бергә, лицензияләүче орган җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында җитәкчегә җибәрелгән карар проекты.

3.3.12. Лицензия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) мөрәҗәгать итүченең 171-ФЗ номерлы федераль законның 2, 8, 9, 10.1, 11, 14.1, 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;

2) 171-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы таләпләрен бозу;

3) мөрәҗәгать итүченең айның беренче көненә һәм лицензияләүче органга лицензия бирү турында гариза кергән көнгә, лицензияләүче орган мөрәҗәгате нигезендә, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып алынган, электрон документ формасында салым органы белешмәсе белән расланган салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлары, шулай ук салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен пенялар һәм штрафлары булу;

4) тапшырылган документларда дөрес булмаган, ялган, шулай ук әгәр тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән статьялар нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, тулы булмаган мәгълүматны ачыклау, яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аның әйләнеше белән бәйле эшчәнлекнең бер төрен гамәлгә ашыруга тиешле лицензия бирү өчен каралган тулы булмаган документлар комплектын тапшыру;

5) мөрәҗәгать итүченең лицензияләүче орган тарафыннан лицензия бирү турында гаризаны теркәү көненнән соң килүче эш көне датасына, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары нигезендә, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган һәм этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнгән түләнмәгән административ штрафы булу.

3.3.13. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензия бирү турында карарга яисә лицензия бирүдән баш тарту турында карарга кул куя һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында кул куелган карар.

3.3.14. Лицензияләү белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензиягә дәгъва кылучыга лицензия бирү яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия бирүдән баш тарту турында карарны бирү (почта аша, яисә электрон почта аша);

лицензия рәсмиләштерү;

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына лицензия турында мәгълүматлар кертү;

лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салу өчен лицензия җибәрү.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) карар, җитәкчегә имзага җибәрелгән лицензия.

3.3.15. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиягә кул куя, мөһер белән раслый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган лицензия.

3.3.16. Лицензиягә дәгъва кылучы сайлап алу нигезендә, лицензияләү белгече алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия яки мондый лицензия бирүдән баш тарту турында карарны шәхсән бирә яки тапшыру турында хәбәре белән заказлы хат итеп җибәрә. Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияне бирү документларны кәгазьдә тапшырганнан соң гамәлгә ашырыла.

Лицензияне бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында теркәлә (13 нче кушымта).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензиягә дәгъва итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән лицензия.

Лицензия бланкларында исәпкә алу сериясе, номеры бар һәм алар катгый хисап документлары булып тора. Лицензия лицензияләүче орган җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана һәм мөһер белән таныклана.

3.3.17. Лицензияләү белгече:

этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнешенә бирелгән, туктатып торылган һәм гамәлдән чыгарылган лицензияләрнең дәүләт җыелма реестрына (алга таба – дәүләт җыелма реестры) лицензия бирү турында белешмәләр кертә (14 нче кушымта);

карарны һәм бирелгән лицензиянең күчермәсен лицензия эше материалларына терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына кертелгән лицензия турында мәгълүматлар.

3.4. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү

3.4.1. Лицензиат шәхсән, яисә электрон почта аша (электрон имза белән имзаланган (таныкланган) документлар рәвешендә) яисә почта аша (белдерү кәгазе һәм кушымталар исемлеге булган кыйммәтле хат) лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаны (9 нчы кушымта, 10 нчы кушымта) лицензияләүче органга тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, алу фактын раслап, электрон формада аның датасы һәм теркәү номеры күрсәтелгән җавапны юллый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында сканерланган, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивына формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

Оешманы үзгәртеп корганда (юридик затларны кушу рәвешендә үзгәртеп корудан һәм үзгәртеп корылган юридик затларның хокук варисын дәүләт теркәвенә алу датасына катнашучы һәр юридик затның алкогольле продукцияне сатуны гамәлгә ашыруга лицензиясе булган очрактан тыш ) лицензияне яңадан рәсмиләштерү әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.17 пунктчаларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Лицензиатның исеме үзгәргән (аны үзгәртеп кормыйча), аның лицензиядә күрсәтелгән яки аның аерым бүлекчәләренең урнашу урыны үзгәргән, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган стационар сәүдә объектына аренда вакыты тәмамланган, сәүдә объектларын ачу яки ябу, лицензиядә күрсәтелгән башка мәгълүматлар үзгәргән очракта, шулай ук лицензияне югалткан очракта, әлеге Регламентның 3.4.2-3.4.9 пунктчаларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.4.2. Лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә башкарыла.

3.4.3. Лицензияләү белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мөрәҗәгатьләрне юллый:

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә эшмәкәрлек эшчәнлегенең (Россия буенча) аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында (техник мөмкинлек булганда), җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаны караган очракта.

Тапшырылган документларга аларның җитәрлек булуын, рөхсәт ителгәнлеген һәм дөреслеген ачыклау юлы белән гамәлдәге закон таләпләренә туры килү-килмәүгә экспертиза үткәрү әлеге Регламентның 3.3.4 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.4. Лицензияләү белгече, документлар экспертизасы (әлеге Регламентның 3.3.4 п.) һәм әлеге Регламентның 3.3.10 п. нигезләмәләре нигезендә әзерләнгән тикшерү акты нигезендә:

лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

әзерләнгән карар проектын, лицензия эше белән бергә, лицензияләүче орган җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияне яңадан рәсмиләштерү яисә аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.5. Лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) мөрәҗәгать итүченең 171-ФЗ номерлы федераль законның 2, 8, 9, 10.1, 11, 14.1, 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;

2) 171-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы таләпләрен бозу;

3) тапшырылган документларда дөрес булмаган, ялган, шулай ук әгәр тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән статьялар нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, тулы булмаган мәгълүматны ачыклау, яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аның әйләнеше белән бәйле эшчәнлекнең бер төрен гамәлгә ашыруга тиешле лицензия бирү өчен каралган тулы булмаган документлар комплектын тапшыру.

3.4.6. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карарга яки лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карарга кул куя һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне яңадан рәсмиләштерү яисә аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында кул куелган карар.

3.4.7. Лицензияләү белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензиатка лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар бирү (почта аша, яисә электрон почта аша);

алдагы лицензиядә күрсәтелгән гамәлдә булу срогын саклап, лицензияне яңадан рәсмиләштерү;

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына яңадан рәсмиләштерелгән лицензия турында мәгълүматлар кертү;

лицензияләүче орган җитәкчесенә кул кую өчен яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне яңадан рәсмиләштерү яисә аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) карар; яңадан рәсмиләштерелгән лицензия, җитәкченең имзасына җибәрелгән мәгълүмат базасына кертелгән белешмәләр.

3.4.8. Лицензияләүче орган җитәкчесе яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне имзалый, мөһер беләнраслый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура документлар алган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән лицензиягә кул кую.

3.4.9. Мөрәҗәгать итүче сайлап алу нигезендә, лицензияләү белгече алкогольле продукцияне ваклап сатуга яңадан рәсмиләштерелгән лицензия, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия яки лицензиатка мондый лицензия бирүдән баш тарту турында карарны шәхсән бирә яки тапшыру турында хәбәре белән заказлы хат итеп җибәрә. Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, яңадан рәсмиләштерелгән лицензия һәм (яки) аңа кушымта бирү документларны кәгазьдә тапшырганнан соң башкарыла.

Яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында теркәлә (13 нче кушымта).

Лицензияне яңадан рәсмиләштергәнчегә кадәр оешма яки аның хокук варисы элек бирелгән лицензия нигезендә эшчәнлек алып бара ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензиат килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән яңадан рәсмиләштерелгән лицензия.

3.4.10. Лицензияләү белгече:

дәүләт җыелма реестрына яңадан рәсмиләштерелгән лицензия турында белешмәләр кертә;

карарны һәм яңадан рәсмиләштерелгән лицензия күчермәсен лицензия эше материалларына терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Дәүләт җыелма реестрына кертелгән яңадан рәсмиләштерелгән лицензия турында белешмәләр.

3.5. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту.

3.5.1. Лицензиат шәхсән, яисә электрон почта аша (электрон имза белән имзаланган (таныкланган) документлар рәвешендә) яисә почта аша (белдерү кәгазе һәм кушымталар исемлеге булган кыйммәтле хат) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны (7 нче кушымта, 8 нче кушымта) лицензияләүче органга тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, алу фактын раслап, электрон формада аның датасы һәм теркәү номеры күрсәтелгән җавапны юллый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында сканерланган, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивына формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.5.2. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.3. Лицензияләү белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мөрәҗәгатьләрне юллый:

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә салымнар һәм җыемнар, пенялар түләү буенча бурычлар һәм салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен штрафлар булу яки булмау турында мәгълүматлар тапшыру турында.

Тапшырылган документларга аларның җитәрлек булуын, рөхсәт ителгәнлеген һәм дөреслеген ачыклау юлы белән гамәлдәге закон таләпләренә туры килү-килмәүгә экспертиза үткәрү әлеге Регламентның 3.3.4 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.4. Лицензияләү белгече, документлар экспертизасы (әлеге Регламентның 3.3.1 п.) һәм әлеге Регламентның 3.3.10 п. нигезләмәләре нигезендә әзерләнгән тикшерү акты нигезендә:

лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында карар проектын әзерли;

әзерләнгән карар проектын, лицензия эше белән бергә, лицензияләүче орган җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә имзага җибәрелгән лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яисә озайтудан баш тарту турында карар проекты.

3.5.5. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) мөрәҗәгать итүченең 171-ФЗ номерлы федераль законның 2, 8, 9, 10.1, 11, 14.1, 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;

2) 171-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы таләпләрен бозу;

3) мөрәҗәгать итүченең айның беренче көненә һәм лицензияләүче органга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза кергән көнгә, лицензияләүче орган мөрәҗәгате нигезендә, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып алынган, электрон документ формасында салым органы белешмәсе белән расланган салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлары, шулай ук салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен пенялар һәм штрафлары булу;

4) тапшырылган документларда дөрес булмаган, ялган, шулай ук әгәр тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән статьялар нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, тулы булмаган мәгълүматны ачыклау, яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аның әйләнеше белән бәйле эшчәнлекнең бер төрен гамәлгә ашыруга тиешле лицензия бирү өчен каралган тулы булмаган документлар комплектын тапшыру;

5) мөрәҗәгать итүченең лицензияләүче орган тарафыннан лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны теркәү көненнән соң килүче эш көне датасына, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган һәм этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнгән түләнмәгән административ штрафы булу.

3.5.6. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында карарга кул куя һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган карар.

3.5.7. Лицензияләү белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензиатка лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки сәбәпләрен күрсәтеп, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында карар бирү (почта аша, яисә электрон почта аша);

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында белешмәләр кертү.

Лицензияләү белгече элек гамәлдә булган лицензиянең оригиналында «озайту» графасында лицензия озайтылган вакытны күрсәтә һәм аны лицензияләүче орган җитәкчесенә имзага җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту яки озайтудан баш тарту турында бирелгән карар, лицензияләүче орган җитәкчесенә имзага җибәрелгән озайту срогы куелган лицензия.

3.5.8. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиягә кул куя, мөһер белән раслый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган лицензия.

3.5.9. Лицензиат сайлавы нигезендә, лицензияләү белгече алкогольле продукцияне ваклап сатуга озайтылган лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга озайтылган лицензияне бирә. Документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, гамәлдә булу срогы озайтылган лицензияне бирү документларны кәгазьдә тапшырганнан соң башкарыла.

Лицензияне бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында теркәлә (13 нче кушымта).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензиат килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гамәлдә булу срогы озайтылган лицензия бирү.

3.5.10. Лицензияләү белгече:

дәүләт җыелма реестрына лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында белешмәләр кертә;

карарны һәм гамәлдә булу срогы озайтылган лицензия күчермәсен лицензия эше материалларына терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт җыелма реестрына кертелгән гамәлдә булу срогы озайтылган лицензия бирү турында белешмәләр.

3.6. Лицензия бирү (гамәлдә булу вакытын озайту, яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны кире алу

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче лицензияләүче органга шәхсән яки почта аша (белдерү кәгазе һәм кушымталар исемлеге белән кыйммәтле хат), яисә электрон почта аша лицензия бирү (лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту, лицензияне яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны кире алу турында ирекле рәвештә гариза бирергә хокуклы.

Гаризаны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, алу фактын раслап, электрон формада аның датасы һәм теркәү номеры күрсәтелгән җавапны юллый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында сканерланган, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивына формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.6.2. Гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы (12 нче кушымта) нигезендә башкарыла.

3.6.3. Лицензияләү белгече:

лицензияне бирү (озайту, яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны карау процедурасын туктату турында карар проектын әзерли;

кул кую өчен карар проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карар проекты.

3.6.4. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензия бирү (гамәлдә булу вакытын озайту, яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны карау процедурасын туктату турында карарга кул куя һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган карар.

3.6.5. Лицензияләү белгече мөрәҗәгать итүчегә почта аша карар яки электрон почта аша белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензияләүче орган җитәкчесе күрсәтмәгә кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән карар.

3.6.7. Лицензияләү белгече мөрәҗәгать итүчегә лицензия бирү (озайту, яңадан рәсмиләштерү) турында гариза белән бергә лицензияләүче органга тапшырылган документларны кире кайтара. Гаризага теркәлгән исемлектә мөрәҗәгать итүчегә документларны кире кайтару турында тамга салына.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

3.7. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булуын яңарту.

3.7.1. Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту өчен лицензиат лицензияләүче органга шәхсән, яисә электрон почта яки почта аша (белдерү кәгазе һәм кушымталар исемлеге булган кыйммәтле хат), лицензиянең гамәлдә булуын туктатуга китергән шартларны бетерү бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләренә яраклы рәвештә нигезләү документларын кушып, гариза тапшыра.

Гаризаны электрон рәвештә тапшырган очракта, лицензияләү белгече, алу фактын раслап, электрон формада аның датасы һәм теркәү номеры күрсәтелгән җавапны юллый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар Portable Document Format (PDF) форматында сканерланган, «zip» яки «rar» форматындагы мәгълүматлар архивына формалаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.7.2. Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Лицензияләү белгече, лицензиат тарафыннан лицензиянең гамәлдә булу шартларын бозуны бетерү фактын раслау максатыннан, планнан тыш тикшерү үткәрүне башкара.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиат тарафыннан лицензиянең гамәлдә булу шартларын бозуны бетерү фактын раслау.

3.7.4. Тапшырылган документлар нигезендә лицензияләү белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки яңартудан баш тарту турында карар проектын әзерли;

лицензияләүче орган җитәкчесенә кул кую өчен карар проектын җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә имзага җибәрелгән лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яисә яңартудан баш тарту турында карар проекты.

3.7.5. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында карар проектына кул куя һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында кул куелган карар.

3.7.6. Лицензияләү белгече:

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында мәгълүматлар кертә;

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында карар бирә (почта аша, яисә электрон почта аша җибәрә).

Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында мәгълүматлар ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат базасына кертелгән белешмәләр, лицензиатка лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында бирелгән (җибәрелгән) карар.

3.8. Лицензиат гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату

3.8.1. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату лицензиатның лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктату турында, лицензияне дә кушып, шәхси гаризасы (11 нче кушымта) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.2. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Лицензияләү белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карар проектын әзерли;

кул кую өчен карар проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң җиде эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карар проекты.

3.8.4. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карарга кул куя һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында кул куелган карар.

3.8.5. Лицензияләү белгече ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында мәгълүмат кертә һәм лицензиатка лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карар бирә (почта аша җибәрә).

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белешмәләр лицензияләү белгече тарафыннан ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына, Дәүләт җыелма реестрына кертелә һәм ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән карар, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына кертү, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматлар.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату датасы булып лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында кул куелган карар датасы тора.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карар, аны сатуны өч эш көне дәвамында туктату максатларында, барлык сәүдә объектларында алкогольле продукция калдыкларын алу өчен нигез булып тора.

3.9. Рәсмиләштергәндә җибәрелгән техник хатага бәйле рәвештә, бирелгән лицензияне алыштыру.

3.9.1. Лицензияләүче орган тарафыннан ачыкланган техник хатасы булган лицензияне алыштыру.

3.9.2. Лицензияләү белгече, техник хата ачыкланган очракта, доклад язуын әзерли һәм тиешле аңлатма белән, аны лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата ачыкланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрелгән аңлатма язуы.

3.9.3. Лицензияләүче орган җитәкчесе бирелгән лицензияне алмаштыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карары турында лицензияләү белгеченә хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән лицензияне алмаштыру турында карар.

3.9.4. Лицензияләү белгече:

бирелгән лицензияне алмаштыру турында карар проектын әзерли;

кул кую өчен карар проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: карар проекты.

3.9.5. Лицензияләүче орган җитәкчесе:

бирелгән лицензияне алмаштыру турында карарга кул куя;

карарны лицензияләү белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән лицензияне алмаштыру турында лицензияләүче орган җитәкчесе имзалаган карар.

3.9.6. Лицензияләү белгече лицензиатка бирелгән лицензияне алмаштыру турында карар җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.9.2-3.9.5 пунктчаларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиат адресына җибәрелгән лицензияне алмаштыру турында карар.

3.9.7. Лицензияләү белгече:

лицензиянең гамәлдә булу вакыты алмаштырыла торган лицензиянең гамәлдә булу срогы тәмамлануга туры килергә тиеш булган лицензияне рәсмиләштерә;

бирелгән лицензияне алыштыру турында ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүмат базасына мәгълүматлар кертә;

лицензияләүче орган җитәкчесенә имзага рәсмиләштерелгән лицензияне җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән лицензия һәм бирелгән лицензияне алмаштыру турында лицензияләрнең дәүләт җыелма реестрына кертелгән белешмәләр.

3.9.8. Лицензияләүче орган җитәкчесе рәсмиләштерелгән лицензияне имзалый, мөһер белән таныклый һәм лицензияләү белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган лицензия.

3.9.9. Лицензияләү белгече, алмаштырыла торган лицензиянең оригиналын лицензияләүче органга кайтарган очракта, алмаштырылган лицензияне лицензиатка яки аның вәкаләтле затына (ышаныч кәгазе булган очракта) бирә.

Бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында теркәлә. Лицензия күчермәсе карар белән бергә лицензия эше материалларына теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензиат яки аның вәкаләтле заты килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән лицензия.

3.9.10. Лицензиат лицензиядә һәм аңа кушымтада техник хата ачыкланган очракта, лицензияләүче органга бирелгән лицензияне алыштыру турында ирекле рәвештә гариза бирә.

Лицензияне алыштыру, лицензия һәм аңа кушымтаны бирү әлеге Регламентның 3.9.3-3.9.9 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала: мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, шикаятьләрне карау, тикшерүләр үткәрү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләү, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тоту рәвешләре:

хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларына экспертиза үткәрү. Экспертизаларның нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү;

Лицензияләү бүлегендә эшләр башкаруга билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрү тора.

Тикшерүләр планлы (ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр уздырганда хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең тәгаен мөрәҗәгате буенча карала ала.

4.2. Хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе тарафыннан агымдагы контрольдә тотыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең үтәлешен контрольдә тоту өчен ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләре турында мәгълүмат тапшырыла.

Белгечләр административ процедураларның вакытларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итә, шулай ук кагыйдә бозуларны бетерү өчен ашыгыч чаралар күрә.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең лицензияләү бүлеге башлыгы һәм территориаль органнары башлыклары гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карауны тикшереп тота.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла торган) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплы башкаручылар законда билгеләнгән тәртиптә җавап тота.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контроль дәүләт хезмәте күрсәткәндә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, шулай ук вазыйфаи затларның, дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе вазыйфаи затының, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә бирелергә мөмкин.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырылырга мөмкин.

КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр - КФҮ җитәкчесенә, КФҮ карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавына) карата КФҮне гамәлгә куючыга бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьне теркәү вакытын бозганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозганда;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшырылуы яки башкарылуы каралмаган документлар яисә мәгълүмат тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый

актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүне таләп иткәндә;

7) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе белгече, КФҮ, КФҮ хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән техник хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозганда;

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып торганда.

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яисә электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе рәсми сайтын (https:// gosalcogol.tatar.ru.), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru) кулланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatarstan.ru) кулланып җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү вакытында алына.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның

вазыйфаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр яисә мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры, электрон почта адресы (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап юлланырга тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүчегә үзенең дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән шартларны раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән соң унбиш эш көне, ә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, КФҮ мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срокларын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Мөрәҗәгать итүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук

китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүче кылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.11. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның вазыйфаи затларына, яисә дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү;

2) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә файдаланылган квалификацияле санлы имзасының гамәлдә булуын тикшерү;

4) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә документлар белән гариза җибәрү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында хәбәр итү.

Мөрәҗәгать итүче, алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе

турында консультацияләр алу өчен, КФҮгә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, рәвеше һәм башка сораулар буенча мәгълүмат бирә һәм, кирәк очракта, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче http://mfc16.tatarstan.ru/ КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтен алуның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, вәкаләтле зат аша яисә электрон формада алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә, КФҮгә, КФҮнең читтән торып эш урынына документлар тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Электрон рәвештә алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6.3.2. Гаризалар кабул итүче КФҮ белгече КФҮ эше регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Документлар пакетын формалаштыру

КФҮ белгече КФҮ эше регламенты нигезендә:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә файдаланылган көчәйтелгән квалификацияле санлы электрон имзасының гамәлдә булуын тикшерә;

документлар пакетын формалаштыра һәм аны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә КФҮ эше регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә җибәрелгән документлар.

Татарстан Республикасы территориясендә
алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм
җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә
алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

# Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен кирәкле документлар исемлеге

Лицензиягә дәгъва итүче оешма, лицензия алу өчен, лицензияләүче органга түбәндәге документларны тапшыра:

1. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында гариза (5 нче кушымта).

2. Лицензиягә дәгъва итүче оешма яисә нотариус тарафыннан расланган гамәлгә кую документларының күчермәләре (күчермәләре нотариус тарафыннан расланмаган очракта, оригиналлары күрсәтелә).

3. Мөрәҗәгать итүченең билгеләнгән күләмдә (җәмәгать туклануы һәм кулланучылар кооперациясе оешмасыннан тыш) устав капиталы (устав фонды) булуын раслаучы документлар, кимендә 300 мең сум күләмендә:

устав капиталын (устав фондын) акчалата түләгәндә - устав капиталын түләүгә исәп-хисап счетына акча күчерүне раслаучы банк җитәкчесе һәм баш хисапчысы имзалаган белешмә, шулай ук беренчел түләү документларының күчермәләре;

устав капиталын (устав фондын) акчалата түләмәгәндә - бәяләү объектларын бәяләү турында хисап һәм мөлкәтне кабул итү-тапшыру актын кушып, акционерның (катнашучының) милкенә хокукын раслаучы документ күчермәсе;

устав капиталын (устав фонды) үз акчалары (аерым алганда, бүленмәгән табыш) хисабына арттырганда - капитализацияләү турында карар кабул ителгән оешма балансын һәм соңгы хисап датасына устав капиталын (устав фондын) арттыруны чагылдыручы балансны кушып, оешманың устав капиталын (устав фондын) үзгәртү турында тиешле карар теркәлгән идарә органы утырышы беркетмәсенең күчермәсе.

4. Мөрәҗәгать итүченең милкендә хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки срогы килешүдә билгеләнеп, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән арендага алынган стационар сәүдә объектларына һәм склад бүлмәләренә ия булуын раслаучы документлар күчермәләре. Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән күчемсез милек объектларына кагылышлы әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, мондый документлар (аларда булган белешмәләр), лицензияләүче органның ведомствоара мөрәҗәгате нигезендә, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә
алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм
җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә
алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен кирәкле документлар исемлеге

Лицензиягә дәгъва итүче оешма, лицензия алу өчен, лицензияләүче органга түбәндәге документларны тапшыра:

1. Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында гариза (6 нчы кушымта).

2. Лицензиягә дәгъва итүче оешма яисә нотариус тарафыннан расланган гамәлгә кую документларының күчермәләре (күчермәләре нотариус тарафыннан расланмаган очракта, оригиналларын күрсәтеп).

3.1. Мөрәҗәгать итүченең милкендә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки срогы шартнамәдә билгеләнгән, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән арендага алынган стационар җәмәгать туклануы объекты (бюджет учреждениеләреннән тыш) булуын раслаучы документлар («Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 10 пунктындагы тугызынчы абзацында, 6 пунктның 3 пунктчасында каралган очраклардан тыш). Бюджет учреждениесе булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан оператив идарәдә, түләүсез файдалануда яки срогы шартнамәдә билгеләнгән, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән арендага алынган стационар җәмәгать туклануы объекты булуын раслый торган документлар тапшырыла («Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 10 пунктындагы унберенче абзацында, 6 пунктның 3 пунктчасында каралган очраклардан тыш). Әлеге пунктчада күрсәтелгән, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән күчемсез милек объектларына кагылышлы әлеге документлар (түләүсез файдалануда җәмәгать туклануы объекты булуын раслаучы документтан тыш) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, мондый документлар (аларда булган белешмәләр), лицензияләүче органның ведомствоара мөрәҗәгате нигезендә, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең (бюджет учреждениеләреннән тыш) милкендә хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдә яки арендага алынган җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү өчен файдаланылырга тиешле җәмәгать туклануы объекты булуын раслаучы документ (лицензияне «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга

салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 6 пунктының 2 пунктчасында каралган очракта биргәндә). Бюджет учреждениесе булган мөрәҗәгать итүче үзенең оператив идарәсендә, түләүсез файдалануда яисә арендага алынган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү өчен файдаланылырга планлаштырылган җәмәгать туклануы объекты булуын раслаучы документларны тапшыра (лицензияне «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 6 пунктының 2 пунктчасында каралган очракта биргәндә);

3.3. Мөрәҗәгать итүченең милкендә, хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдә яки арендага алынган вагон-ресторан (вагон-кафе, вагон-буфет, вагон-бар), су судносы, һава судносы булу һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең аларда җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтү хокукын раслаучы документлар (шәһәрара һәм халыкара элемтәдәге гомуми файдаланудагы тимер юл һәм су транспортында, шулай ук гомуми файдаланудагы транспортка карамаган тимер юл һәм су транспортында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату хокукын күздә тоткан лицензияне биргәндә, аерымланган бүлекчә урнашкан урын урынына әлеге вагон-ресторан (вагон-кафе, вагон-буфет, вагон-бар), су судносының аларга тиешле транспорт чаралары өчен билгеләнгән тәртиптә бирелгән теркәү мәгълүматлары күрсәтелә).

4. Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтә башлау турында хәбәрнең күчермәсе. Әгәр документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, техник мөмкинлек булганда, бу документ лицензияләүче органның ведомствоара мөрәҗәгате нигезендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту өчен кирәкле документлар исемлеге

1. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза (7 нче кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза (8 нче кушымта).

2. Элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

# Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар исемлеге

1. Юридик зат үзгәртеп корылганда оешма, лицензия алу өчен, Административ регламентка 1 нче кушымта нигезендә билгеләнгән тәртиптә лицензияләүче органга документлар тапшыра.

Юридик затларны кушу, берләштерү яки үзгәртү рәвешендә үзгәртеп корганда Административ регламентка 1 кушымта нигезендә лицензия алу өчен билгеләнгән тәртиптә, Административ регламентка 1 нче кушымтаның 3 пунктында каралган документлардан тыш, лицензияләүче органга документлар тапшырыла.

2. Оешманың исемен үзгәрткәндә (аны үзгәртеп кормыйча) яисә аның урнашу урынын үзгәрткәндә лицензиат гамәлгә кую документларында тиешле үзгәрешләр теркәлгәннән соң 30 көн дәвамында лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) оешма–лицензиат тарафыннан яки нотариаль расланган үзгәрешләр кертүне раслаучы гамәлгә кую документларының күчермәләре (күчермәләре нотариус тарафыннан расланмаган очракта, оригиналлары күрсәтелә);

в) элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

3. Лицензиядә күрсәтелгән аерымланган бүлекчәләрнең урнашу урыннары үзгәргән очракта (шул исәптән өстәмә сәүдә объектларын ачу), лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган стационар сәүдә объектын арендалау срогы тәмамланган очракта, лицензиат лицензияне яңадан рәсмиләштерергә кирәк булган шартлар барлыкка килгән көннән алып утыз көн эчендә лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) мөрәҗәгать итүченең милкендә хуҗалык алып бару өчен бирелгән, оператив идарәдәге яки срогы килешүдә билгеләнеп, бер ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән арендага алынган стационар сәүдә объектларына һәм склад

бүлмәләренә ия булуын раслаучы, нотариаль таныкланган документлар күчермәләре.

в) җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтүне башлау турында хәбәр күчермәсе (җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштергәндә)

в) элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

4. Лицензиядә күрсәтелгән сәүдә объекты ябылуга бәйле мәгълүматларны үзгәрткәндә лицензиат лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) элек бирелгән лицензиянең оригиналлары һәм ябыла торган сәүдә объектына кушымта.

5. Лицензия югалган очракта лицензиат лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) лицензияне югалтуны раслаучы документлар (лицензияне югалту сәбәпләре турында аңлатма һәм массакүләм мәгълүмат чараларында лицензияне югалту факты турында мәгълүмат бастырып чыгару).

6. Лицензиядә күрсәтелгән бүтән мәгълүматларны үзгәрткәндә лицензиат лицензияләүче органга түбәндәгеләрне тапшыра:

а) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (9 нчы кушымта) яисә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (10 нчы кушымта);

б) мондый үзгәрешләр китереп чыгарган конкрет юридик фактлар турында белешмәләрне раслаучы документлар, шулай ук алар белән бәйле өстәмә материаллар;

в) элек бирелгән лицензиянең оригиналы.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Җитәкче

____________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)

____________________________

# ГАРИЗА

______________________________________________________________________________

(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

______________________ ел *вакытка*
алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүне сорый

Оешманың
урнашу урыны ______________________________________________________________

(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _______________________________________ КПП _______________________________________

(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН______________________________________________________________________________

Исәп-хисап счеты ________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(банк исеме)

Телефон __________________________ электрон почта ____________________________________

Оешма җитәкчесе имзасы ______________________________________________

(Ф.И.А.)

М.У. «_____» ___________ 20__ ел

| № п/п | Сәүдә объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объектының урнашу урыны [1]адресы | Сәүдә объектының кадастр номеры | Сәүдә объектының мәйданы | Сәүдә объектының КПП | Сәүдә объектының эш режимы | Стационар сәүдә объекты координаталарының билгеләмәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[1] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст; 2015, № 18, 2707 ст; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Җитәкче

____________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)

____________________________

# ГАРИЗА

______________________________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

_______________________ елга җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүне *сорый*.

Оешманың
урнашу урыны ______________________________________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _______________________________________ КПП __________________________________________
(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН___________________________________________________________________________________________

Исәп-хисап счеты ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________________
(банк исеме)

Телефон __________________________ электрон почта ____________________________________

Оешма җитәкчесе имзасы ____________________________________________________
(Ф.И.А.)

М.У. «_____» ___________ 20__ ел

| № п/п | Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объектының урнашу урыны [2]адресы | Җәмәгать туклануы объектының кадастр номеры | Җәмәгать туклануы объектының мәйданы | Җәмәгать туклануы объектының КПП | Җәмәгать туклануы объектының эш режимы | Стационар җәмәгать туклануы объекты координата-ларының билгеләмәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[2] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст; 2015, № 18, 2707 ст; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Җитәкче

___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)

___________________________

# ГАРИЗА

___________________________________________________________________________________________

(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

_______________________________________ *елга*

(серия, лицензиянең реестр номеры)

алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне озайтуны сорый

Оешманың
урнашу урыны _________________________________________________________________________

(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _____________________________________ КПП _____________________________________________

(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН

_________________________________________________________________________________________

Исәп-хисап счеты _________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________________________

(банк исеме)

Телефон ___________________________ электрон почта __________________________________

Оешма җитәкчесе имзасы ______________________________________________________

(Ф.И.А.)

М.У. «_____» ___________ 20__ ел

| № п/п | Сәүдә объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объектының урнашу урыны [3]адресы | Сәүдә объектының кадастр номеры | Сәүдә объектының мәйданы | Сәүдә объектының КПП | Сәүдә объектының эш режимы | Стационар сәүдә объекты координата-ларының билгеләмәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[3] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст; 2015, № 18, 2707 ст; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Җитәкче

____________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)

____________________________

# ГАРИЗА

______________________________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

________________________________________ *ел*_____________________________ вакытка
(серия, лицензиянең реестр номеры)

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне озайтуны сорый

Оешманың
урнашу урыны ___________________________________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _______________________________________ КПП _______________________________________________
(оешманың теркәлү урыны буенча)

ОГРН

___________________________________________________________________________________________

Исәп-хисап счеты ___________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________________
(банк исеме)

Телефон ____________________________ электрон почта ____________________________________

Оешма җитәкчесе имзасы _____________________________________________________
(Ф.И.А.)

М.У. «_____» ___________ 20__ ел

| № п/п | Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объектының урнашу урыны [4]адресы | Җәмәгать туклануы объектының кадастр номеры | Җәмәгать туклануы объектының мәйданы | Җәмәгать туклануы объектының КПП | Җәмәгать туклануы объектының эш режимы | Стационар җәмәгать туклануы объекты координата-ларының билгеләмәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[4] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст; 2015, № 18, 2707 ст; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Җитәкче
___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)
___________________________

# ГАРИЗА

___________________________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

оешманың урнашу урыны ___________________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ___________________________________ ОГРН _______________________________________________

алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерүне сорый

№___________________ сериясе_______ _ _ _ ___________реестр номеры белән

гамәлдә булу срогы _____дән _ _ _ _гә кадәр

______________________________________________________________________*бәйле рәвештә.*
(лицензияне яңадан рәсмиләштерү зарурлыгының сәбәбе күрсәтелә)

___________________________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________________________

Элемтә өчен телефон ___________________

Оешма җитәкчесе имзасы ___________________________________________________
(Ф.И.А.)

М.У. «_____» ___________ 20__ ел

| № п/п | Сәүдә объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объектының урнашу урыны [5]адресы | Объектның кадастр номеры | Сәүдә объектының мәйданы | Сәүдә объектының КПП | Сәүдә объектының эш режимы | Стационар сәүдә объекты координата-ларының билгеләмәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[1] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст; 2015, № 18, 2707 ст; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта

Җитәкче
___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)
___________________________

# ГАРИЗА

____________________________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

оешманың урнашу урыны ___________________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН _________________________________ ОГРН ____________________________________________

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерүне сорый

№___________________ сериясе______ _ _ _ ___________реестр номеры белән

гамәлдә булу срогы _____дән _ _ _ _гә кадәр

_________________________________________________________________*бәйле рәвештә.*
(лицензияне яңадан рәсмиләштерү зарурлыгының сәбәбе күрсәтелә)

____________________________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________________________

Элемтә өчен телефон __________________

Оешма җитәкчесе имзасы ______________________________________________
(Ф.И.А.)

М.У. «_____» __________ 20__ ел

| № п/п | Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Җәмәгать туклануы объектының урнашу урыны адресы[6] | Җәмәгать туклануы объектының кадастр номеры | Җәмәгать туклануы объектының мәйданы | Җәмәгать туклануы объектының КПП | Җәмәгать туклануы объектының эш режимы | Стационар җәмәгать туклануы объекты координата-ларының билгеләмәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

[6] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә адрес структурасы күрсәтелә. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 48, 6861 ст; 2015, № 18, 2707 ст; № 33, 4853 ст.).

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта

Җитәкче
___________________________

(ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы)
___________________________

# ГАРИЗА

_____________________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм (яки) кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше)

оешманың урнашу урыны ____________________________________________________________
(оешманың теркәлү адресы)

ИНН ___________________________________ ОГРН ______________________________________________

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булуын туктатуны сорый)

№____________________ сериясе_______ _ _ _ ___________реестр номеры белән

гамәлдә булу срогы _____дән _ _ _ _гә кадәр

Элемтә өчен телефон ___________________

Оешма җитәкчесе имзасы ____________________________________________________
(Ф.И.А.)

М.У. «_____» ___________ 20__ ел

| № п/п | Сәүдә объектының /Җәмәгать туклануы объектының төре һәм атамасы | Сәүдә объектының /җәмәгать туклануы объектының урнашу урыны | Сәүдә объекты/җәмәгать туклануы объекты КПП |
|---|---|---|---|

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 12 нче кушымта

# Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр бирү (гамәлдә булу вакытын озайту, яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаларны теркәү ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Оешма исеме, элемтә телефоны | Оешма ИНН | Документларны тапшырган затның ФИА | Документларны кабул иткән белгечнең ФИА | Мөрәҗәгать итү максаты (лицензия бирү, озайту, яңадан рәсмиләштерү) | Сәүдә объектының яисә җәмәгать туклануы объектының атамасы һәм урнашу урыны | Кабул ителгән карар (лицензияне бирү, озайту, яңадан рәсмиләштерү яки бирү, озайту, яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту) | Лицензиянең гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |

Искәрмә:
Журнал кәгазьдә һәм электрон рәвештә алып барыла.
Кәгазь журнал шнурланган, номер сугылган, лицензияләүче орган җитәкчесе мөһере һәм имзасы белән расланган булырга тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 13 нче кушымта

# Лицензияләрне бирүне теркәү ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Лицензия алу датасы | Лицензиянең сериясе, реестр номеры һәм кушымта номеры | Лицен-зиянең гамәлдә булу срогы | Оеш-ма исеме | Лицензияләнә торган объектның урнашу урыны | Лицензия бирүне рәсмиләштергән затның ФИА, имзасы | Лицензия алган затның ФИА, имзасы | Лицензия алган затның паспорт сериясе, номеры | Ышанычнамә номеры, бирелү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 14 нче кушымта

# Татарстан Республикасы территориясендә этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүгә һәм әйләнешенә бирелгән, туктатылган һәм гамәлдән чыгарылган лицензияләрнең ДӘҮЛӘТ ҖЫЕЛМА РЕЕСТРЫ

| Оешма исеме, ИНН | Оешманың урнашу урыны (район, адрес) | Сәүдә объектының яисә җәмәгать туклануы объектының атамасы һәм урнашу урыны (район, адрес) | Лицензия һәм кушымталарның сериясе, реестр номеры | Сәүдә объектының теркәү номеры | Лицензиянең гамәлдә булу срогы | Туктатып тору датасы | Яңарту датасы | Гамәлдән чыгару датасы | Туктатып тору, яңарту, гамәлдән чыгару сәбәбе | Карарның датасы, номеры (бирү, туктатып тору, яңарту, гамәлдән чыгару) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 15 нче кушымта

## Территориаль органнар турында мәгълүмат

| Территориаль орган атамасы | Урнашу урыны адресы, электрон почта адресы, җәмәгать транспортының тукталыш мәйданчыклары | Хезмәт күрсәтелүче муниципаль берәмлекләр | Телефон |
|---|---|---|---|
| Әлмәт | 423457, Әлмәт шәһәре, Гафиятуллин ур., 26<br>Электрон адрес: alc71@almet.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында ДК «Нефтьче» тукталышына кадәр барырга:<br>- троллейбуслар 1,6<br>- автобус 5 | Әлмәт, Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Ютазы районнары | (8553) 22-21-66, 22-21-33 |
| Арча | 422000, Арча шәһәре, Банк ур., 2а<br>Электрон адрес: alc41@arsk.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында<br>- «Мелиоратор аша Арча станциясе - Педагогика көллияте» маршруты буенча «Үзәк»;<br>- «Арча станциясе - Көнчыгыш мәчете» маршруты буенча «Мәдәният йорты» тукталышына кадәр барырга. | Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба, Теләче районнары | (84366) 3-28-79, 3-28-93 |
| Яшел Үзән | 422540, Яшел Үзән шәһәре, Засорин ур., 9<br>Электрон адрес: alc81@zeldol.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында «Муравейник» СЙ тукталышына кадәр барырга.<br>6 автобус | Яшел Үзән, Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш районнары | (84371) 5-85-15, 4-58-78 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Казан | 420107, Казан шәһәре,<br>Һ.Такташ ур., 94<br>Электрон адрес:<br>alc33@kazan.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында «Һади Такташ урамы» тукталышына кадәр барырга:<br>- автобуслар № 5, 25, 43, 68, 71, 77 | Казан шәһәре,<br>Биектау,<br>Лаеш,<br>Питрәч,<br>Балык Бистәсе<br>районнары | (843)<br>278-91-93,<br>277-94-96 |
| Чаллы | 423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Корчагин бульвары, 2а йорт (10/34а)<br>Электрон адрес:<br>alc21@chelny.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында «Универсам» тукталышына кадәр барырга.<br>- зур автобуслар 2, 3, 10, 11, 21, 26<br>- кече автобуслар 7, 22, 1, 35, 42, 43<br>-трамвайлар 2, 6, 8, 9, 10, 12 | Чаллы шәһәре,<br>Әгерҗе,<br>Актаныш,<br>Алабуга,<br>Мамадыш,<br>Менделеевск,<br>Минзәлә,<br>Тукай<br>районы | (8552)<br>71-52-22,<br>71-29-08 |
| Түбән Кама | 423584, Түбән Кама шәһәре, Бызов ур., 20 а<br>Электрон адрес:<br>alc61@nizn.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында «Универсам» тукталышына кадәр барырга<br>зур автобуслар 5,13,14,<br>56 кече автобусы;<br>-»19 микрорайон»<br>трамвайлар 2,8 | Түбән Кама,<br>Аксубай,<br>Зәй,<br>Мөслим,<br>Сарман,<br>Чирмешән<br>районнары | (8555)<br>36-63-76,<br>36-63-85 |
| Чистай | 422980, Чистай шәһәре,<br>Бебель ур., 121д<br>Электрон адрес:<br>alc51@chistopol.tatalc.ru<br>Җәмәгать транспортында «Электр челтәрләре», «Укытучы йорты», «Тегү фабрикасы» тукталышларына кадәр барырга: автобуслар | Чистай,<br>Алексеевск,<br>Әлки,<br>Яңа Чишмә,<br>Нурлат, Спас<br>районнары | (84342)<br>5-15-50,<br>5-49-85 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1,6,7,11,12,21,24,30 | | |

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 16 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар реквизитлары**

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе | (843) 2789200 | cla@tatalc.ru |
| ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары | (843) 2789278 | Rustem.Arslanov@tatalc.ru |
| Лицензияләү бүлеге башлыгы | (843) 2789199 | Huzin.Ildar @tatalc.ru |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының эшләр башкару бүлеге | (843) 2647774 | prav@tatar.ru |

**ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары**

| Территориаль орган атамасы | Телефон | Адрес | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Чаллы территориаль органы | (8 8552) 715222, 714722 | 432800, Чаллы шәһәре, Корчагин ур., 10/ 34 | alc21@chelny.tatalc.ru |
| Түбән Кама территориаль органы | (8 8555) 366376, 366385 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Бызов ур., 20а | alc61@nizn.tatalc.ru |
| Әлмәт территориаль органы | (8 8553) 336706, 336682, | 423461, Әлмәт шәһәре, Шевченко ур., 88, литер А | alc71@almet.tatalc.ru |
| Яшел Үзән территориаль органы | (8 271) 58515, 58672 | 422520, Яшел Үзән шәһәре, Засорин ур., 9 | alc81@zeldol.tatalc.ru |
| Арча территориаль органы | (8 266) 32879, 32269 | 422010, Арча шәһәре, Банк ур., 2а | alc41@arsk.tatalc.ru |
| Чистай территориаль органы | (8 242) 51550, 51019 | 422950, Чистай шәһәре, Бебель ур., 121 | alc51@chist.tatalc.ru |